

Ркаил Зәйдулланын китаплары башкорт, торек, урыс телләрендә нәшер ителгән, аерым әсәрләре, инглиз, vзбәк, казах һәм чуваш телләренә тәржемә ителеп, торле басмаларда донья кvргән. Шулай ук анын башка телләрдән татарчага vз шигъри тәржемәләре дә байтак. Шулар арасында яратып, тәмле-тәмле тәржемәләре безгә таныш: югары дәрәҗәдә яратып тәржемә ителгәннәр. Шулар арасында Мордовиянен халык шагыйре Камиль Абидулла улы Тангалычевнын да иҗатыннан шигырьләр циклын тәржемә итте Ркаил Рафаил улы Зәйдуллин. Шуларнын берничәсен сезгә дә тәгъдим итәбез, тvбәндә укырсыз.

Кvрше регионыбыз Чувашиядә туган Татарстаннын халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәvләт премияләре лауреаты, Татарстан Дәvләт Шурасы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла vткен каләмле, туры сvзле публицист. Татар милләтенен тарихи язмышы һәм бvгенге хәле, дин, тел, мәдәният һәм милләт алдына килеп баскан башка бик кvп торле мәсьәләләр анын һәрвакыт игътибарын vзенә җәлеп итә. Ул аларнын берсенә дә битараф тvгел, момкинлеге булган саен аларга матбугат аша vзенен монәсәбәтен белдерә килә. Монын остенә, Ркаил Зәйдулла vзенен укучыларына әдәбият мәсьәләләренә һәм сәнгать кешеләре иҗатына багышланган кvп санлы мәкаләләре һәм тәнкыйди язмалары белән дә таныш.

Сvз башына кайтып, Камиль Тангалычевнын русчадан Ркаил Зәйдулланын татарчага тәржемә-ләренен берничәсен тәгъдим итәбез.

**Сыркыды авылында**

*Якташым Һади Такташ истәлегенә*

Сыркыды шунда ук...
Әмма
Кvченгән икән кvптән...
...Юлбашчы рәсемен Шәхми
Оенә алып киткән.

Ташландык ой тvбәсеннән

Кояш узды,
Хәерсез...
Ватылган арба копчәге
Тәгәрәде, әйтерсен.

Мокамайлар курасында
Югалды ул аларып:
Иртән кояшны урлауда
Гаепләрләр малайны.

Мокамай
Эзли шагыйрьне,
Тартып ватык арбаны.
Аерылды да тәгәрмәчләр,
Донья буйлап таралды.

Атларны да
Алып киткән
Ат карагы – бу вакыт.
Эзли хәзер vз шагыйрен
Ботен донья буйлатып.

Ай балкый кvктә.
Ярымай...
Исә йолдызлар жиле.
Тиздән печән чабарга дип
Хәйрулла абзый килер.
Тезен чvгә алмаганга
Шагыйрьнен нигезенә,
Мәнге елар бер карт каен,
Яшь кояр vзе генә...

**Мишәрләр**

Сыкрап елый жилдә тирә-ягым.
Жир-анадан килгән ишарә:
Әрвахлары эзсез югалган да,
Үксез калган
Безнен мишәрләр.

Әрвахларны эзли киткән Тәнре.
Кардәшләрем! Халык!
Әгәр сез
Очратсагыз аны, яктырыгыз, –
Югалмасын Тәнре хәбәрсез.

Авылында иркенлекне сакла,
Тик дивар кор жиде ятларга.
Кайтачак бит Тәнре.
Туры килер
Кылган гамәленне акларга.

Табармы тик әрвахларны Тәнре?
Тапмас, тапмас, беләм тапмасын.
Килер вакыт – ботен vксезләргә
Алмаштырыр нәсел бабасын...

**Туган тел**

Безгә һаман жилләр каршы булды,
Ачы булды, карлы, янгырлы...
Һәм арынды халык  “артык йоктән” –
Туган телен... ташлап калдырды.

Тел шуышты, остерәлде алга,
Телсез калган халкын эзләде.
Ят кавемнәр ана ташлар атты,
Тел
Калкынырга теләп тезләнде...

Кvкләр ишетмәде бу халыкны.
Иблис адаштырган далада
Эзләп тапты да тел, сулыш орде –
Кабат кайтты халык Аллага.

Ак биләvгә биләп vз халкын тел,
Уян инде, диеп инәлде.
Кырлар буйлап, гvя кvк йозеннән,
Татар авылына юнәлде.

Телгә йозен ачты Тәнре шулчак,
Теләкләрен тоеп, ин тәvдә
Бәби булып биләнәсе килде
Тел биләгән сихри биләvдә.

Житте алар онсез бер авылга.
Гадәти бер авыл – юлдагы...
Мескен халык –
Шул борынгы сабый –
Жир-анага сыенып елады.

* * *

Тәрәз тобе...
Әни гәжит тоткан.
Анда минем шигырь. Һәм рәсем –
Улы карап тора.
Ә шигырьне
Укый алмый әни, кvрәсен.

Укый алмый әни.
Шигырьләрем
Язылмаган ана телендә.
Һәрбер сvзем монда онсез кош кvк,
Һәрбер сvзем – сулган гол генә...

Ул улынын ни язганын белми.
Тәкъдир мина ниләр язганын.
Чамалыйдыр: Жан авазын минем
Ана житкерәлмәv газабын.

Дәшми-тынмый дисбе тарта әни,
Кvз алдынан vтә гомере.
Мин тошенмәм инде бу доганы,
Ул укымас минем шигырьне.

**Киселгән икмәк**

Киселгән икмәк шикелле,
Жир урталай ярылган;
Кара упкын кvзгә карый
Жирнен шул ярыгыннан.

Берботен икмәкне шулай
Әнкәй дә кисә иде, –
Донья ярылмаган иде,
Жир әле исән иде.

Донья урталай киселгән...
Кем аны шулай кискән?!
Бер ярда – әткәем туган,
Бер ярда – әнкәм vскән...

*Фотода: шагыйрьлэр Ркаил Зэйдулла белэн Камиль Тангалычев, уртада - академик Рашид Сюняев.*